**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**14 ноябрь 2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында халык җыены карар бирә:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,
- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш 300 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Ленина урамына вак таш сатып алу, ташу, салу);
- урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, авыл урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу хезмәтләре, юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Үзәк урам, 39 йорт, Балан-Бүләк авылы, Ленина урамы, 39А йорт.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы ___________ А.М.Мөхәмәтшин